**СОВЕТ НИКОЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422627 с. Никольское,
ул. Центральная, д.35
тел: 4-31-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

422627 Никольский авылы,
Әзәк урамы, 35 нчы йорт,
тел: 4-31-44

**2022 елның«11» ноябре** **60-1номер**

## КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Никольский авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 октябрендәге 19 номерлы карарына үзгәрешләр кертү**

««Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 16 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» 2019 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, карар итәм:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Никольский авыл җирлеге Советының 2018 елның 10 октябрендәге 19 номерлы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Никольский
авыл җирлеге Советы рәисе** **Э.Х.Алеев**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Никольский авыл җирлеге Советының
2022 елның «11» ноябрендәге 60-1 номерлы
карарына кушымта.

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү**

1) 3 пунктның 17 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;
2) 128.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Тиешле тәртиптә төзелгән һәм җир кишәрлекләре дәүләт кадастр исәбенә куелган милекчеләр өчен стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында карар кабул итү мөмкинлеге, бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, тулысынча юкка чыгарылмаска тиеш.;

3) 94 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гомуми файдаланудагы барлык парковкаларда, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналарын, төзелешләрен һәм корылмаларын, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан биналарны да кертеп), ял итү урыннары янында, I, II төркем инвалидлар белән идарә ителә торган транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны ташучы транспорт чаралары өчен бушлай парковка өчен урыннарның кимендә 10 проценты (әмма кимендә бер урыны) бүлеп бирелә. III төркем инвалидларга бу кагыйдә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә кагыла. Күрсәтелгән транспорт чараларында "Инвалид" тану билгесе билгеләнергә һәм әлеге транспорт чаралары турындагы мәгълүмат инвалидларның федераль реестрына кертелергә тиеш.»